**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының**
**Зур Кукмара авыл җирлеге**
**муниципаль берәмлеге**

# КАРАР

**21 ноябрь, 2024 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Янсыбы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Зур Кукмара авыл җирлеге Уставы нигезендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2024 елның 21 ноябрендә үткәрелгән гражданнар җыененың беренче, икенче, өченче этаплары нәтиҗәсе буенча йомгаклау беркетмәсе төзелде:

«Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк кешеләр кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Янсыбы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2025 елда үзара салымны 1500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

**тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау** (урамнарны яктырту өчен энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру);

**су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау** (Су суырту башняларын буяу өчен буяулар сатып алу, су суырту башняларын буяу, су суырту башняларын ремонтлау, артезиан кое насосларын алу һәм урнаштыру; устройство, Яңа сүүткәргеч челтәрләрен төзү, ремонтлау, проект-смета документациясен әзерләү, килешү буенча хезмәтләр һәм эшләр өчен түләү);

**җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү** (Янсыбы авылында чишмәләр төзү, ремонтлау һәм территориясен төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү);

**беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү** (янгын гидрантларын һәм комплектлаучыларны сатып алу, урнаштыру һәм ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү);

**торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту** (юлларга вак таш җәю, юлларга вак таш җәеп, чокырларны төзекләндерү (ямочный ремонт), проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; Янсыбы авылының урам-юл челтәрен карап тоту, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру; Янсыбы авылы урамнарын асфальтлау, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

**торак пункт территориясен төзекләндерү** (балалар уен мәйданчыгын сатып алу, урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; ял зоналарын булдыру һәм төзекләндерү буенча чаралар үткәрү; Сабантуй бәйрәме уздыру урыны территориясен төзү һәм төзекләндерү; Янсыбы авылы территориясен төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү)?

«КАРШЫ ТҮГЕЛ» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 244 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 125 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 123 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 2 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Янсыбы авылында халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк кешеләр кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Янсыбы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2025 елда үзара салымны 1500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

**тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау** (урамнарны яктырту өчен энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру);

**су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау** (Су суырту башняларын буяу өчен буяулар сатып алу, су суырту башняларын буяу, су суырту башняларын ремонтлау, артезиан кое насосларын алу һәм урнаштыру; устройство, Яңа сууткәргеч челтәрләрен төзү, ремонтлау, проект-смета документациясен әзерләү, килешү буенча хезмәтләр һәм эшләр өчен түләү);

**җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү** (Янсыбы авылында чишмәләр төзү, ремонтлау һәм территориясен төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү);

**беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү** (янгын гидрантларын һәм комплектлаучыларны сатып алу, урнаштыру һәм ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү);

**торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту** (юлларга вак таш җәю, юлларга вак таш җәеп, чокырларны төзекләндерү (ямочный ремонт), проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; Янсыбы авылының урам-юл челтәрен карап тоту, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру; Янсыбы авылы урамнарын асфальтлау, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

**торак пункт территориясен төзекләндерү** (балалар уен мәйданчыгын сатып алу, урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; ял зоналарын булдыру һәм төзекләндерү буенча чаралар үткәрү; Сабантуй бәйрәме уздыру урыны территориясен төзү һәм төзекләндерү; Янсыбы авылы территориясен төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү)?

«КАРШЫ ТҮГЕЛ» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Зур Кукмара
авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Хәнәфиев